Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Янсуар авыл җирлеге

Янсуар авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

«25» август, 2021 года № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, 2017 елның 21 августындагы 60 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе хакындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш эшчәнлеге, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга карата район халкының хокукларын үтәү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга (алга таба - Генераль план).

2. Генераль план проекты буенча гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлеге башкарма комитетына (алга таба - җирлек башкарма комитеты) йөкләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Янсуар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бөтен территориясендә (алга таба – Янсуар авыл җирлеге) торак пунктлар өлешендә - Янсуар авылы, Нырсуар авылы, Райково авылы, Тегермән Тавы авылы, Талкыш авылы) уздырыла.

Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Янсуар авылы халкы өчен: 2021 елның 28 сентябрендә 9.00 сәг. тә Янсуар мәдәният йорты фойесында (ТР, Питрәч районы, Янсуар авылы, Үзәк ур., 1) ;

- Нырсуар авылы халкы өчен: 2021 елның 28 сентябрендә 10.00 сәгатьтә Янсуар мәдәният йорты фойесында (ТР, Питрәч районы, Янсуар авылы, Үзәк ур., 1);

- Райково авылы халкы өчен: 2021 елның 28 сентябрендә Пушкин урамындагы 23 нче йорт янында 13.00 сәгатьтә;

- Тегермән Тавы авылы халкы өчен: 2021 елның 28 сентябрендә Гоголь урамындагы 6 нчы йорт янында 14.00 сәгатьтә;

- Талкыш авылы халкы өчен: 2021 елның 28 сентябрендә 15.00 сәгатьтә Кооператив урамындагы 10 нчы йорт янында.

4. Җирлекнең башкарма комитетына:

4.1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Вперед» («Алга») район газетасында гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат бастырырга.

4.2. Янсуар авыл җирлеге халкына Генераль план проектының эчтәлеге турында мәгълүматны житкерү максатында Генераль план проектының демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештыру, җирле үзидарә органнары вәкилләре чыгышлары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында генераль план проектын эшләүчеләр чыгышлары: 422786, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Янсуар ав., Үзәк ур., 1 йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр, көндезге 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш вакыты).

4.3. Әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә һәм срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4.4. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында билгеләнгән тәртиптә бәяләмә әзерләргә һәм бастырып чыгарырга.

5. Генераль план проекты буенча гавами тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынучы затлар тарафыннан җирлек Башкарма комитетына эш көннәре буенча мәгълүматны 8 сәгатьтән 12 сәгатькә кадәр, 13 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр 2021 елның 26 мартына кадәр (шул көнне кертеп), Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Янсуар авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, 422786, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Янсуар авылы, Үзәк ур., 1. адресы буенча язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

6. Янсуар авыл җирлегендә яшәүчеләр Интернет челтәрендәге генераль план проекты белән «Авыл җирлекләре - Янсуар авыл җирлеге» бүлегендә (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Территориаль планлаштыруның Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтында https://fgistp.economy.gov.ru/ таныша алалар.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Янсуар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Янсуар авыл җирлеге башлыгы В.Н. Таланов